ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«28» май 2025 ел № 541

**2025 елга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында юл эшләре муниципаль программасын муниципаль юл фонды акчалары исәбеннән раслау турында**

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә, Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2025 елга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында юл эшләре муниципаль программасын муниципаль юл фонды акчалары исәбеннән расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы И. М. Хәсәновка йөкләргә.

Җитәкче А. Г. Хисаметдинов

Арча муниципаль районы
башкарма комитеты карары белән
**РАСЛАНДЫ**
«_28_» ___май___ 2025 ел № _542_

# 2025 ЕЛГА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ГОМУМИ ФАЙДАЛАНУДАГЫ ҖИРЛЕ ӘҺӘМИЯТТӘГЕ АВТОМОБИЛЬ ЮЛЛАРЫНДА МУНИЦИПАЛЬ ЮЛ ФОНДЫ АКЧАЛАРЫ ИСӘБЕННӘН ЮЛ ЭШЛӘРЕНЕҢ МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАСЫ.

**ПРОГРАММА ПАСПОРТ**

| | |
|---|---|
| Программа исеме | 2025 елга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында муниципаль юл фонды акчалары исәбеннән юл эшләренең муниципаль программасы. |
| Программаны эшләү өчен нигез | 1. Россия Федерациясе Бюджет кодексы.<br>2. 2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль закон.<br>3. Татарстан Республикасы Бюджет Кодексы.<br>4. 2024 елның 28 ноябрендәге “2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турына” 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы.<br>5. 2025 елга Татарстан Республикасы юл эшләре программасы. (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 21 февралендәге “2025 елга Татарстан Республикасында гомуми файдаланудагы юлларда юл эшләре турында” 107 номерлы карарына кушымта.<br>6. Арча муниципаль районының 2025 елга һәм 2026 һәм 2027 елларның план чорына бюджеты.<br>7. Арча район Советының 2013 елның 12 октябрендәге “Муниципаль юл фондын төзү турында һәм муниципаль юл фондының бюджет ассигнованиеләрен формалаштыру һәм куллану тәртибен раслау хакында” 232 номерлы карары.<br>8. 2025 елга гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге юлларда юл эшләре муниципаль программаларын гамәлгә ашыруга муниципаль юл фондлары ассигнованиеләре күләмнәре. |
| Программа Координаторлары | 1. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы.<br>2. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы.<br>3. “Юл эшләре программаларын финанслау дирекциясе” ДБУ<br>4. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты. |
| Программаның Заказчысы | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты. |
| Программаны төп эшләүчеләр | Арча муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге. |

| | |
|---|---|
| Программаның максатлары һәм бурычлары | 1. Арча муниципаль районы торак пунктларындагы гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген, күпфатирлы йортларның ишегалды территорияләрен, күпфатирлы йортларның ишегалды территорияләренә керү юлларын капиталь ремонтлауны һәм ремонтлауны тәэмин итү.<br>2. Арча муниципаль районы торак пунктларының юл-урам челтәрен юллар төзү, реконструкцияләү һәм ремонтлау юлы белән норматив хәлгә китерү.<br>3. Гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыру. |
| Программаның максатчан күрсәткечләре | Муниципаль юл фонды акчаларын үзләштерү һәм туплау. |
| Гамәлгә ашыру сроклары | 2025 ел |
| Финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | 2025 елга төп муниципаль юл фонды ассигнованиеләре күләме 47 339 100,00 сум тәшкил итә.<br>Муниципаль юл фонды акчаларының калдыклары 2025 елның 1 гыйнварына 5 508 657,86 сум тәшкил итә.<br>(Гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыру).<br>Финанслау чыганаклары:<br>1. Россия Федерациясе территориясендә җитештерелә торган автомобиль һәм турыдан-туры куыла торган бензинга, дизель ягулыгына, дизель, карбюратор һәм инжектор двигательләре өчен мотор майларына акцизлар.<br>2. Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр рәвешендәге кертемнәр (Финанслау чыганагы варианты).<br>3. Физик һәм юридик затлардан кергән акчалар, шул исәптән иректе иганәләр (Финанслау чыганагы варианты).<br>2025 ел лимитлары – 47 339 100,00 сум.<br>2025 елның 1 гыйнварына калдык - 5 508 657,86 сум. |
| Программаны гамәлгә ашыруның көтелә торган ахыргы нәтиҗәләре | 1. Халыкның иминлек дәрәҗәсен күтәрү.<br>2. Юл хәрәкәте иминлеген арттыру.<br>3. Районның инвестицияләр җәлеп итүчәнлеген арттыру.<br>4. Хуҗалык итүче субъектларның һәм тулаем муниципаль районның социаль-икътисадый үсеше. |

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Муниципаль юл фонды Россия Федерациясе Бюджет кодексының 179.4 статьясындагы 5 пункты нигезендә төзелә һәм файдаланыла.

1.2. Муниципаль юл фонды-гомуми файдаланудагы җирле (муниципаль) әһәмиятле автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген финанс белән тәэмин итү (төзү һәм ремонтлау)максатларында кулланылырга тиешле муниципаль берәмлек бюджеты акчаларының бер өлеше, шул исәптән юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү, күпфатирлы йортларның ишегалды территорияләрен, торак пунктларның күпфатирлы йортларының ишегалды территорияләренә керү юлларын капиталь ремонтлау һәм ремонтлау чараларын гамәлгә ашыру өчен.

1.3. Юл фонды акчалары максатчан билгеләнештә була һәм юл эшчәнлеген тәэмин итүгә бәйле булмаган ихтыяҗларга тартып алынырга яисә тотылырга тиеш түгел.

## 2. 2025 елгы юл фондын булдыру чыганаклары

2.1. Юл фондының бюджет ассигнованиеләре күләме чираттагы финанс елына һәм план чорына җирле бюджет турында Арча муниципаль районы Советы карары белән җирле бюджет керемнәренең фаразлана торган күләменнән ким булмаган күләмдә раслана:

1. Россия Федерациясе территориясендә җитештерелә торган автомобиль һәм турыдан-туры куыла торган бензинга, дизель ягулыгына, дизель һәм карбюратор (инжектор) двигательләр өчен мотор майларына чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән расланган дифференциацияләнгән бүлү нормативлары нигезендә Арча муниципаль районы бюджетына күчерелә торган акцизлар.

Муниципаль юл фонды бюджет ассигнованиеләре күләме, хисап финанс елында фактта кергән һәм аны формалаштырганда әлеге пунктта күрсәтелгән җирле бюджет керемнәре күләме фаразланган аерманы исәпкә алып, чираттагы финанс елында төзәтелергә тиеш.

2.2. Юл фондының агымдагы финанс елында файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләре чираттагы финанс елында юл фондының бюджет ассигнованиеләрен арттыруга (юл хәрәкәте иминлеге чараларын тәэмин итүгә) җибәрелә.

## 3. 2025 елгы юллар фонды акчаларын тоту юнәлешләре

3.1. Муниципаль юл фонды акчалары юнәлдерелә:

1. Гомуми файдаланудагы җирле (муниципаль) әһәмиятле автомобиль юлларын проектлау, төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, ремонтлау һәм карап тотуга;
2. Торак пунктлардагы күпфатирлы йортларның ишегалды территорияләрен, күпфатирлы йортларның ишегалды территорияләренә керү юлларын капиталь ремонтлау һәм ремонтлауга.
3. Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыруга.

3.2. 2025 елга Юл фонды бюджет ассигнованиеләре күләмен объектлар буенча бүлү әлеге программага кушымтада күрсәтелгән. Әлеге кушымталар 2025 елда муниципаль юл фонды акчаларының бер өлешен юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү чараларына куллану турында Татарстан Республикасы Хөкүмәте карары нигезендә төзелгән.

## 4. Юл фонды акчаларын тотуны тикшереп тору

Юл фонды акчаларын тотуны тикшереп торуны Арча муниципаль районы башкарма комитеты, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының 9 нчы территориаль бүлеге, “Юл эшләре программаларын финанслау дирекциясе” ДБУ гамәлгә ашыра.

*2025 елга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге юлларында юл эшләре муниципаль программасына муниципаль юл фонды акчалары исәбеннән кушымта*

2025 елга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге юлларында юл эшләре программасына кертелгән җирле әһәмияттәге объектлар исемлеге

| № п/п | Объект исеме | Км егәрлеге, пог. м, м2 | Гамәлдәге бәяләрдә капитал салулар, мең сумнар |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1 | Арча шәһәренең үзәк өлешендә автопарковкалар, җәяүлеләр кичүләре (Банк ур. һәм аның тирәсендәге территория) | Озынлыгы. 168м, мәйдан 1182м2 | 11 850 570 |
| 2 | Подгорная урамында тротуар кору, стадионга төшү | Озынлыгы 359м, мәйдан 606м2 | 7 457 286 |
| 3 | Маяковский урамы буенча тротуарның дәвамы | Озынлыгы 35м, мәйдан 53м2 | 577 533 |
| 4 | Вагыйзовлар ур., РОО бинасы каршында парковка | Озынлыгы 70м, мәйдан 358м2 | 2 047 692 |
| 5 | Кәче авылындагы мәдәният йорты һәм ФАП каршындагы парковканы төзекләндерү | Озынлыгы 47м, мәйдан 251м2 | 1 616 868 |
| 6 | Арча шәһәренең Ватан ур. 2/2 футбол манежы өчен юл һәм машина кую урыны | Озынлыгы 41м, мәйдан 1203м2 | 8 462 768 |
| 7 | Арча ш., Банк ур., 26а йорт “Алгарыш” яшьләр үзәге” МБУ территориясен төзекләндерү | Озынлыгы 140м мәйдан 782,6м2 | 8 606 112 |
| 8 | М. Гафури урамын норматив хәлгә китерү | Озынлыгы 147 м, мәйдан 662м2 | 2 833 123 |
| 9 | Совет мәйданындагы парковканы төзекләндерү (тротуар плиткасыннан тузган өслекне алыштыру) | Озынлыгы 48м, мәйдан 545м2 | 3 887 148 |
| | **Барысы:** | | 47 339 100,00 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **2025 елга МДФ планы буенча барлыгы** | | | **47 339 100,00** |
| | | | |
| I. | 2025 елгы бюджет йөкләмәләрен үтәү | - | - |
| II. | БДД буенча ирекле калдык акчалары исәбеннән гамәлләр, шул исәптән: | - | - |
| 1 | “Г. Курсави исемендәге күппрофильле лицей” МБМУ юлында ясалма тигезсезлекләр урнаштыру | Билгеләр:8 шт.<br>ИДН:2 шт. | 301 503,52 |
| 2 | Арча шәһәренең Көнбатыш урамында 22 нче йорттан 44 нче йортка кадәр ясалма тигезсезлекләр урнаштыру | Билгеләр:17 шт.<br>ИДН:4 шт. | 603 720,01 |
| 3 | Арча шәһәренең Тукай урамында 27нче йорттан 37нче йортка кадәр ясалма тигезсезлекләр урнаштыру | Билгеләр:4 шт.<br>ИДН:1шт. | 126 845,64 |
| 4 | Левитан урамында ясалма тигезсезлекләр урнаштыру (алмаштыру һәм билгеләр) | Билгеләр:8 шт.<br>ИДН:2 шт. | 266 857,03 |
| 5 | Шаляпин 10 йортка ясалма тигезсезлекләр урнаштыру | Билгеләр: 4 шт.<br>ИДН:1 шт. | 127 305,78 |
| 6 | Мәктәптә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны тәэмин итү өчен тукталыш пунктлары төзү. Павильон, утырту мәйданчыгы, керү урыны, юл билгесе, аншлаг.1. Арча ш. Бакый Урманче ур. | Билгеләр:2 шт.<br>Автопав:1 шт. | 241 214,69 |
| | 2. Түбән Мәтәскә авылы “Г. Курсави исемендәге күппрофильле лицей” МБМУ | Озынлык 43м, мәйдан 123м2<br>Билгеләр:2 шт.<br>Автопав:1 шт. | 1 339 684,86 |
| | 3. “С.З. Габдрахманова исемендәге Яңа Кенәр урта мәктәбе” МБМУ | Озынлык 71м, мәйдан 230м2<br>Билгеләр:2 шт.<br>Автопав:1 шт. | 2 188 131,62 |
| 7 | Җәяүлеләр светофорлары өчен ак уклы өстәмә секцияләр урнаштыру | 27 шт. | 313 394,71 |
| **2025 елның 1 гыйнварына МДФның фактик калдыгы буенча барлыгы** | | | **5 508 657,86** |

- - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - -

Муниципаль юл фондларының бюджет ассигнованиеләре кысаларында ел саен шушы килешүнең 5 статьясындагы 3 пункты нигезендә төзелә